## Бакиев

## Сахаб Хафизович



1910 нчы елның 2 апрелендә Мөслим районы Мәллә авылында туа.

Гаиләдә Сахабтан башка 4 бала була: абыйлары – Мөхәммәтдин, Салих, апасы- Рәшидә һәм 1 сеңлесе. Мөхәммәтдин абыйсы Мәлләдә озак еллар колхоз председателе булып эшли, Салих – механизатор, ә Рәшидә апасы укытучы була.

Бөек Ватан сугышы башланганчы Мөслим районы Үрәзмәт авылы мәктәбендә директор булып эшли. Шул елларда география-тарих фәннәрен укытучы кызга – Зоха Хафиз кызына өйләнә. Сугышта алгы сызыкларда связист булып эшли.

Сугыш беткәч, яшь гаиләне Яңа Усы авылы мәктәбенә җибәрәләр. Сахаб Хафизович озак еллар завуч булып эшли. 1963 нче елларда директор була. 3-4 ел эшли.

Директорлыктан алгач – физика-математика фәннәрен укыта.